КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 6 апрель г.Казань № 420

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 18 сентябрь, 879 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 18 сентябрь, 879 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 14 декабрь, 1228 нче, 2022 ел, 1 август, 739 нчы, 2022 ел, 15 декабрь, 1331 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибендә:

16 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«конкурста катнашучы чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор

компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

әлеге карар белән расланган Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү комиссиясе составында:

комиссия составыннан М.Н.Садыйковны, И.Н.Хәлфиевны, Г.Р.Шакированы, И.З.Яруллинны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Миңнуллин Марсель Мансур улын | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры, комиссия рәисен |
| Зарипов Раушан Булат улын | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы урынбасарын |
| Сабиров Марат Тәлгать улын | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсенең хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлек итү бүлекчәсе мөдирен |
| Шәрәфетдинов Илнур Хәсән улын | «Иҗтимагый сәламәтлек һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибын. |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин